**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

БОЕРЫК
03.06.2024

РАСПОРЯЖЕНИЕ
8-р

Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

Республикада хәрби хезмәткә контракт төзүче Татарстан гражданнары өстәмә акчалата түләүләр ала:

Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 2 ноябрендәге 787 номерлы Указы һәм РФ Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 787 номерлы йөкләмәсе нигезендә, мобилизацияләнгән һәм контракт төзегән хәрби хезмәткәрләргә 195 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү каралган.

2024 елның маеннан Оборона министрлыгы белән контрактка кул куйганнарга бер тапкыр бирелә торган төбәк түләүләре күләме - 505 мең сумга кадәр арттырылды (Татарстан Республикасы Рәисе Указы 26.10.2023 ел №738)

Моннан тыш, контракт хезмәтенә керүчеләр районнан ярдәм чаралары сыйфатында өстәмә түләүләр ала.

Хәрби хезмәткә керергә теләүчеләргә ярдәм итү масштабларын киңәйтү өчен, 2024 елның 01 июненнән 6 айдан да ким булмаган вакытка хәрби хезмәт узу турында контракт төзегәндә, бер тапкыр бирелә торган муниципаль өстәмә түләүне бирергә.

Муниципалитеттан өстәмә түләү предприятиеләрдән җибәрелә торган бюджеттан тыш акчалар хисабына башкарыла.

Ул гражданның яисә ялгыз яшәүче гражданның гаиләсенең җирле бюджет исәбеннән күрсәтелә торган социаль ярдәм чараларын күрсәтү өчен кеше башына уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алынмый.

Актаныш районы хәрби комиссариаты аша контракт буенча хәрби хезмәткә кергән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган түләү күләме:

- күрсәтелгән контракт төзегәннән соң, 2024 елның 1 июненнән хәрби хезмәт узу турында килешү төзегән - 100000 сум;
- контракт хезмәтенә җәлеп итүгә этәргеч биргән һәм булышкан өчен -50000 сумга кадәр.;

Күрсәтелгән контрактны төзү датасына яшәү урыны Актаныш районы территориясендә булган гражданнар өчен;

2024 елның 1 июненнән хәрби хезмәт узу турында килешү төзегән, күрсәтелгән контрактны төзегәннән соң - 100000 сум;

- контракт хезмәтенә җәлеп итүгә этәргеч биргән һәм булышкан өчен-10000 сумга кадәр.;

Акчалар кредит оешмаларында Актаныш районы Хәрби комиссариаты биргән исемлекләр буенча, контракт имзаланганнан соң, автомат рәвештә хәрби хезмәткәрләрнең ачылган счетларына күчерелә.

Контрактны имзалауга ярдәм иткән өчен физик затка акчалар контрактны имзалаганнан соң, Актаныш районы Хәрби комиссариаты биргән исемлекләр, шартнамә һәм башкарылган эшләр акты буенча автомат рәвештә күчерелә.

Акчалата түләүләрне документлаштыруны һәм контрольне район Башлыгының коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмчесе А.Ф.Фәрдиевка йөкләргә.

Район Башлыгы Л.Р.Зарипов